# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 16 Бәйрәкә ав. 05.06.2024 ел

### Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2005 елның 21 июлендәге «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында»гы 97-ФЗ санлы федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2024 елның 18 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проекты хакында»гы 7 санлы карары, 2024 елның 29 маендагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен, 2024 елның 3 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 51 санлы карары белән расланган, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан 2024 елның 25 гыйнварындагы дәүләт теркәү саны RU165433042024001 булган (алга таба – Устав) «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Уставның 7 маддәсендәге 1 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.2. Уставның 38 маддәсендәге 1 пунктының 27 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;

1.3. Уставның 55 маддәсендәге 1 пунктының 10 пунктчасындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1.4. Уставның 61 маддәсендәге 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

"13) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы белешмәләргә аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы)»;

1.5. Уставның 80 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе" турындагы 80 маддә»

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы җирлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү чаралары булып түбәндәгеләр тора:

1) тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru; 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) таныклыгы яисә “Ютазы таңы” («Ютазинская новь») вакытлы матбугат басмасында (2011 елның 7 декабрендә бирелгән ЭЛ № ФС77-47613 санлы массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) таныклыгы;

2) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру: http://jutaza.tatarstan.ru/;

3) җирлекнең Бәйрәкә авылы, Ютазы урамы, 13в йорт адресы буенча урнашкан торак пункт территориясендәге мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Бәйрәкә авылы, Ютазы урамы, 14А йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге хокукый җирлек башлыгы акты.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://jutaza.tatarstan.ru / һәм басмалар челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru (ЭЛ ММЧны теркәү турында 2014 елның 17 декабрендәге ФС77-60244 санлы таныклыгы).

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина